ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.10.2021 ел Баулы шәһәре №189

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге «Баулы муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең 2021 елга планлы күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 11 декабрендәге 1130 номерлы карарына һәм максатчан сарыф ителергә тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәренә үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 декабрендәге «Баулы муниципаль районы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең 2021 елга планлы күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 239 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 2 нче пункт өстәргә:

«2. Әлеге карарның 1 нче пункты нигезендә, Баулы муниципаль районының бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган

керемнәрдән административ-идарәче персоналның хезмәт хакын түләүгә җибәрелгән чыгымнар күләме күрсәтелгән керемнәр күләменең 30 процентыннан артмаска тиеш.»;

2 нче һәм 3 нче пунктларны 3 нче һәм 4 нче пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Свежинкинага йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров